ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03. 11. 2021 Олы Кайбыч ав. 449

2022 елга «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмалары һәм сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2022 елга:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмалары һәм сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын кушымтада каралганча;

сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмәләр коэффициентын 0,5 күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында, «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Петуховага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы
Башкарма комитет
Җитәкченең беренче урынбасары Э. Х. Заһидуллина

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021е. «03» 11 449 номерлы
карарына кушымта

**2022 елга «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучына елына сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | Биш еллык укыту срогы | Җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Нәфис сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореографик сәнгать | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрад-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театраль сәнгать | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |